КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 апрель г.Казань № 328

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планына раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Чаралар планын җаваплы башкаручылар булып торучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары аның үтәлешен тәэмин итә.

3. Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары булмаган башка дәүләт органнарына чаралар планын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына ел саен 1 февральгә кадәр Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм

коммуникацияләр агентлыгына аның үтәлеше турында мәгълүмат тапшырырга, шулай ук Чаралар планын гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары булмаган бүтән дәүләт органнарына тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына ел саен, 1 мартка кадәр, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Чаралар планын үтәү барышы турында хисап тапшырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 24 апрель, 328 нче
карары белән расланды

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы

| Т/с | Чара исем | Җаваплы үтәүчеләр | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Матбугат релизларын җибәрү юлы белән басма, электрон һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат тарату.<br>Интервью һәм матбугат конференцияләрен оештыру.<br>Коррупциягә каршы тору буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган чаралар турында массакүләм мәгълүмат чараларына җиткерү | Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | квартал саено, 2030 елга кадәр |
| 2. | Коррупциягә каршы тору өлкәсендә халыкка хокукый белем бирү буенча телетапшырулар циклын чыгаруны тәэмин итү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ел саен, 2021 елга кадәр (елга кимендә 12 телетапшыру) |
| 3. | Җәмгыятьтә коррупциягә карата түзеп тормаучанлык формалаштыру һәм коррупциягә каршы тәртипне пропагандалау булдыру максатларында республика телеканалларында социаль | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ел саен, 2021 елга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | юнәлешле мәгълүмати-аңлату һәм мәгълүмати-имидж видеоматериаллары эшләү һәм трансляцияләүне тәэмин итү (Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә) | | |
| 4. | Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек игътибарын коррупция проблемасына җәлеп итү, халыкка коррупция күренешләре белән бәйле хокук бозулар нәтиҗәләрен аңлату, коррупция күренешләренә бәйле хокук бозуларны профилактикалау буенча гражданнарның актив позициясен формалаштыру, шулай ук гражданнарның коррупциягә каршы һәм хокукый дөньяга карашын формалаштыру максатында республика массакүләм мәгълүмат чаралары арасында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга махсус журналист конкурсы үткәрү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ел саен, 2021 елга кадәр |
| 5. | «События недели» – «Атна вакыйгалары» газетасында «Коррупциягә каршы тору өлкәсендә хокукый белем бирү» тематикасы буенча материаллар бастырып чыгаруны тәэмин итү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ай саен, 2021 елга кадәр |
| 6. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгына һәм аңлаешлылыгына ярдәм итү максатларында күрсәтелгән органнар җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары катнашында интервью һәм матбугат конференцияләрен оештыру һәм үткәрү | Исполнительные органы государственной власти Республики Татарстан, органы местного самоуправления муниципальных образований (по согласованию), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | 2030 елга кадәр (елга кимендә 1 тапкыр) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 7. | Коррупционерларны фаш итү, вазыйфаи затларны алар биләгән вазыйфалардан азат итү һәм аларны җаваплылыкка тарту фактлары турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша Татарстан Республикасында яшәүчеләргә җиткерү | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | ел саен, 2030 елга кадәр |
| 8. | Эшмәкәрләр белән профилактик эш, шул исәптән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча өйрәтү семинарлары үткәрү | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) | квартал саен, 2030 елга кадәр |
| 9. | Массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасында эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларын бәяләү белән алып барыла торган эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүмат һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларының хокукый хәлен камилләштерү турында тәкъдимнәр урнаштыру | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) | елга бер тапкыр 2021 елга кадәр |
| 10. | Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләре, торак мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларны контрольдә тоту системасы турында басмаларда мәгълүмат бирү, телепрограммаларда (телетапшыруларда) һәм радиопрограммаларда (радиотапшыруларда) яңалыклар сюжетлары әзерләү юлы белән халыкны мәгълүмат белән тәэмин итү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | даими, 2030 елга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 11. | Милли мәктәпләрдә укучыларның туган телләрендә башкарылган эшләреннән файдаланып «Коррупциягә «ЮК»!» һәм балалар рәсемнәре «Гадел яшәргә кирәк!», һөнәри белем бирү оешмалары укучылары арасында иҗади эшләрдән «Закон сагында, коррупциягә каршы!» дигән темага иҗат күргәзмәләре үткәрү һәм тематик стендлар оештыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе (килешү буенча) | ел саен, 2021 елга кадәр |
| 12. | Мәгариф учреждениеләрендә хокукый белемнәр тарату максатларында мәгариф учреждениеләренең профессор- укытучы составы арасында Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру темасына фәнни-гамәли тикшеренү эшләре конкурсын үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе (килешү буенча) | ел саен, 2021 елга кадәр |
| 13. | Фәнни-дискуссион, шулай ук мәгълүмати-агарту иҗтимагый акцияләре циклын уздыруга дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен белем бирү оешмалары укучылары, Татарстан Республикасы югары белем бирү оешмалары студентлары, галимнәр һәм эшләүче яшьләр катнашында коррупциягә карата түзеп тормый торган мөнәсәбәт булдыруга, хокукый белем һәм хокукый культура дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән сатып алуларны гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | ел саен, 2021 елга кадәр |
| 14. | Татарстан Республикасы югары белем бирү оешмалары студентлары арасында коррупциягә каршы тәртип булдыруга, шул исәптән коррупциягә каршы юнәлештәге социаль реклама конкурсларын үткәрүгә юнәлдерелгән махсус агитация-иҗтимагый акцияләр циклын үткәрүне оештыру (видеоконкурс, плакатлар, фотокросс һ.б.). | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | даими, 2021 елга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Әлеге эшләрне файдаланып тематик стендлар оештыру һәм күргәзмәләр үткәрү | | |
| 15. | Яшьләр оешмалары эшчәнлеген һәм үткәрелә торган иҗади конкурсларны яктырту максатыннан мәгълүмат әзерләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ярты елга бер тапкыр, 2030 елга кадәр |

______________________